Татарстан Республикасы
Чистай муниципаль районы
Кече Талкыш авыл җирлеге Советы
Карары

2019 елның 27 нче июне № 66/1

Татарстан Республикасы
Чистай муниципаль районы
«Кече Талкыш авыл җирлеге»
муниципаль берәмлеге Уставына
үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында

2009 елның 21 нче мартындагы 02-08-02-2019 номерлы Чистай шәһәр прокуратурасының протестын карап, “Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында”гы 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 44 статьясы нигезендә, “Муниципаль берәмлекләр уставларын дәүләт теркәвенә алу турында”гы 2005 елның 21 июлендәге 97-ФЗ номерлы Федераль законга таянып, “Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында”гы 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 7 статьясы белән, Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы “Кече Талкыш авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Уставының 84-86 статьяларына нигезләнеп, Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Кече Талкыш авыл җирлеге Советы

Карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы “Кече Талкыш авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Уставына түбәндәге үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертергә:

1.1. 6 статьяның 1 пунктындагы 13 пунктчасында “күзәтүчесез(караучысыз) калган хайваннарны тоту һәм асрау чаралары” сүзләрен “хуҗасыз калган(яшәүче) хайваннар белән эшчәнлек алып бару” сүзләренә алмаштырырга;

1.2. 16 статьяның 3 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Территориаль иҗтимагый үзидарә гамәлгә ашырыла торган территория чикләре, тиешле территориядә яшәүче халык тәкъдиме буенча, җирлек Советы тарафыннан билгеләнә.»;

1.3. 22 статьяда:

3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Җирлектә халык җыены үткәрелергә мөмкин:

1) составына күрсәтелгән торак пункт керә торган авыл җирлеге (муниципаль район) чикләрен үзгәртү мәсьәләсе буенча, әлеге торак пункт территориясен башка җирлек(муниципаль район) территориясенә кертеп була торган торак пунктта;

2) җирлек составына керүче торак пунктта әлеге торак пункт территориясендә үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча;

3) авыл торак пунктында авыл торак пункты старостасы кандидатурасын тәкъдим итү мәсьәләсе буенча, шулай ук авыл торак пункты старостасы вәкаләтләрен вакытыннан алда туктату мәсьәләсе буенча;

4) авыл торак пунктында граждannar җыены шулай ук муниципаль хезмәт турында Россия Федерациясе законнарында каралган очракларда муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүгә бәйге үткәргәндә бәйге комиссиясе составына кандидатуралар тәкъдим итү максатларында үткәрелә.».

түбәндәге эчтәлекле 9 пункт өстәргә:

«9. Әлеге статьяда бәян ителгәнчә, сайлау хокукына ия булган торак пункт, яки җирлек халкының яртысыннан артык граждannar булганда, җыенны үткәрү хокукы саклана. Торак пунктта сайлау хокукына ия кешеләрнең яртысыннан артыгы җыенда катнаша алмаса, күрсәтелгән торак пункт кергән муниципаль берәмлек уставы нигезендә, граждannar җыенын үткәрү турында Карар кабул

ителгән көннән соң, бер айдан да артмый торган вакытка этаплап уздырыла. Шул ук вакытта элек гражданнар җыенында катнашкан затлар, киләсе тавыш бирү этапларында катнашмый. Җыенда катнашучыларның яртысыннан артыгы тавыш биргән булса, гражданнар җыены карары кабул ителгән дип санала.».

1.4. 47 статьяның 2 пунктына түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә::

«- җирлек территориясендә яшәүче хуҗасыз хайваннар буенча эшчәнлек алып бара.»;

1.5. 86 статьясына түбәндәге эчтәлекле 4 өлеш өстәргә:

«4. Әлеге Уставка кертелгән, җирлек Советы депутатлары санын арттыручы, яки киметүче үзгәрешләр әлеге Уставка үзгәрешләр кертү турындагы муниципаль норматив хокукый актны кабул иткән җирлек Советының вәкаләтләре вакыты чыкканнан соң үз көченә керә.».

2. Әлеге карарны законнарда билгеләнгән тәртиптә дәүләт теркәве өчен җибәрергә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Кече Талкыш авыл җирлеге торак пунктлары территориясендә махсус мәгълүмат стендларына урнаштыру юлы белән игълан итәргә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Кече Талкыш авыл җирлеге башлыгы Г. Н. Федотовка йөкләргә.

Кече Талкыш авыл
җирлеге башлыгы Г.Н.Федотов